КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 3 декабрь г.Казань № 1089

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 декабрь, 1063 нче; 2015 ел, 8 май, 333 нче; 2015 ел, 17 июнь, 444 нче; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2016 ел, 30 март, 181 нче; 2016 ел, 25 май, 349 нчы; 2016 ел, 13 сентябрь, 640 нчы; 2016 ел, 21 сентябрь, 670 нче; 2016 ел, 28 ноябрь, 877 нче; 2017 ел, 25 гыйнвар, 29 нчы; 2017 ел, 28 апрель, 254 нче; 2017 ел, 26 июнь, 430 нчы; 2017 ел, 12 август, 568 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 766 нчы; 2017 ел, 11 декабрь, 967 нче; 2018 ел, 27 март, 176 нчы; 2018 ел, 10 май, 343 нче; 2018 ел, 29 август, 735 нче; 2018 ел, 20 декабрь, 1198 нче; 2019 ел, 16 гыйнвар, 12 нче; 2019 ел, 13 февраль, 102 нче; 2019 ел, 6 июнь, 474 нче; 2019 ел, 31 октябрь, 974 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1246 нчы; 2020 ел, 24 июль, 618 нче; 2020 ел, 11 ноябрь, 1012 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025

елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре | Программаның бюджет ассигнованиеләре күләмнәре федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 476 502 703,93 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:<br>2014 ел - 30 831 624,92 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 3 276 380,3 мең сум);<br>2015 ел - 40 434 999,8 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 10 287 192,8 мең сум);<br>2016 ел - 42 370 549,4 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 12 319 020,9 мең сум);<br>2017 ел - 39 584 370,3 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 8 141 860,8 мең сум);<br>2018 ел - 65 440 908,71 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 15 892 374,91 мең сум);<br>2019 ел - 63 989 186,46 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 20 146 126,41 мең сум);<br>2020 ел - 64 789 729,44 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 18 140 215,1 мең сум);<br>2021 ел - 64 576 279,3 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 16 153 040,9 мең сум);<br>2022 ел - 60 952 945,4 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 12 113 382,3 мең сум);<br>2023 ел - 3 532 110,2 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 2 318,7 мең сум).<br>2023 – 2025 елларга акчалар күләме фараз характерында, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»; |

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Программаның бюджет ассигнованиеләре күләмнәре федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 476 502 703,93 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:

2014 ел - 30 831 624,92 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 3 276 380,3 мең сум);

2015 ел - 40 434 999,8 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 10 287 192,8 мең сум);

2016 ел - 42 370 549,4 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 12 319 020,9 мең сум);

2017 ел - 39 584 370,3 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 8 141 860,8 мең сум);

2018 ел - 65 440 908,71 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 15 892 374,91 мең сум);

2019 ел - 63 989 186,46 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 20 146 126,41 мең сум);

2020 ел - 64 789 729,44 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 18 140 215,0 мең сум);

2021 ел - 64 576 279,3 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 16 153 040,9 мең сум);

2022 ел - 60 952 945,4 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 12 113 382,3 мең сум);

2023 ел - 3 532 110,2 мең сум (шул исәптән капиталь кертемнәргә - 2 318,7 мең сум).

2023 – 2025 елларга акчалар күләме фараз характерында, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»;

2 нче кушымтаны яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә;

«2014 – 2025 елларга гомуми белем бирүне үстерү, шул исәптән инклюзив белем бирү һәм әлеге өлкә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында (алга таба - ярдәмче программа):

ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, ярдәмче программасын финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, ярдәмче программасын финанслау күләмнәре | Ярдәмче программа чараларын финанслау күләмнәре федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 214 638 293,48 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:<br>2014 ел - 17 205 591,64 мең сум;<br>2015 ел - 18 902 517,8 мең сум;<br>2016 ел - 18 161 160,9 мең сум;<br>2017 ел - 18 684 936,6 мең сум;<br>2018 ел - 20 796 481,8 мең сум;<br>2019 ел - 21 922 502,2 мең сум;<br>2020 ел - 30 383 867,24 мең сум;<br>2021 ел - 32 398 109,7 мең сум;<br>2022 ел - 32 674 691,1 мең сум;<br>2023 ел - 3 508 434,5 мең сум.<br>2023 – 2025 елларга акчалар күләме фараз характерында, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»; |

«Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (Ярдәмче программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары)» юлында:

утыз бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«цифрлы, табигый-фәнни, гуманитар һәм технологик профильләрдәге төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен матди-техник базасын яңарткан авыл җирлегендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары санын 0,5 мең берәмлеккә кадәр арттыру»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«квалификация күтәрүне узган гомуми белем бирү оешмаларының педагогик хезмәткәрләре өлешен, шул исәптән һөнәри осталыкны өзлексез арттыру үзәкләрендә, 40 процентка кадәр арттыру;

цифрлы белем бирү мохитен кертү максатларында җиһазландырылган гомуми белем бирү оешмаларының өлешен 5,61 процентка кадәр арттыру;

цифрлы белем бирү мохитенең федераль мәгълүмат-сервис платформасына керү мөмкинлеге бирү юлы белән аларның тору урынына бәйсез рәвештә сыйфатлы белем алуның тигез шартлары булдырылган укучылар өлешен 20 процентка кадәр арттыру;

цифрлы белем бирү мохитенең федераль мәгълүмат-сервис платформасы сервисын кулланучы педагогик хезмәткәрләрнең өлешен 40 процентка кадәр арттыру;

төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда цифрлы белем бирү мохитенең федераль мәгълүмат-сервис платформасы сервисларыннан файдаланучы мәгариф оешмалары өлешен 30 процентка кадәр арттыру»;

2 бүлектә:

28 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

28. «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Заманча мәктәп» төбәк проекты чараларын гамәлгә ашыру (шул исәптән авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында цифрлы һәм гуманитар профильләрнең төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен матди-техник база булдыру (яңарту) чаралары; гомуми белем бирү эшчәнлеген бары тик адаптацияләнгән төп гомуми белем бирү программалары буенча гына гамәлгә ашыручы оешмаларда матди-техник базаны яңарту буенча чаралар; авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында, табигый-фәнни һәм технологик юнәлештәге мәгариф үзәкләрен булдыру һәм аларның эшләве буенча чаралар; гомуми белем бирү оешмалары базасында «Кванториум» балалар технопаркларын төзү буенча чаралар)

«Заманча мәктәп» төбәк проекты төп гомуми һәм урта гомуми белем дәрәҗәләрендә белем бирүнең һәм тәрбиянең, белем бирү технологияләренең белем алучыларның база күнекмәләрен һәм күнекмәләрен үзләштерүен тәэмин итә торган яңа ысулларын кертүгә, аларны белем бирү процессына өйрәтүгә һәм җәлеп итүгә мотивацияләүне арттыруга, шулай ук «Технология» фән өлкәсен укыту ысулларының эчтәлеген яңартуга һәм камилләштерүгә юнәлдерелгән.

Башлангыч, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында челтәр рәвешендә гомуми

белем бирү программалары гамәлгә ашырылачак. 2022 елның 1 сентябренә гомуми белем бирүнең яңартылган федераль дәүләт белем бирү стандартларын һәм үрнәк төп гомуми белем бирү программаларын кертү буенча чаралар комплексы гамәлгә ашырылачак.

2019 - 2024 елларда Татарстан Республикасы «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проектының түбәндәгеләргә юнәлдерелгән чараларда катнашачак:

авыл җирлегендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында цифрлы һәм гуманитар юнәлештәге төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен матди-техник база булдыру (яңарту);

гомуми белем бирү эшчәнлеген бары тик җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программалары буенча гына гамәлгә ашыручы оешмаларда матди-техник базаны яңарту;

авыл җирлегендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешмаларында, табигый-фәнни һәм технологик юнәлешле белем бирү үзәкләрен төзү һәм эшләтү;

«Кванториум» балалар технопаркларының гомуми белем бирү оешмалары базасында балалар технопарклары төзү.»;

28.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«28.1. «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында цифрлы һәм гуманитар профильнең төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен матди-техник база булдыру (яңарту) чаралары

Авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында цифрлы һәм гуманитар профильнең төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен матди-техник база булдыру (яңарту) чаралары кысаларында Татарстан Республикасында 2019 елда авыл районнарының 97 мәктәбе базасында цифрлы һәм гуманитар профиль мәгариф үзәкләре булдырылды, 2020 елда - 139 авыл мәктәбе базасында (үсә баручы нәтиҗә белән).

Үзәкләрне җиһазландыру өчен (күбесенчә «Технология», «Мәгълүмат», «Тормыш эшчәнлеге иминлеге нигезләре» өлкәләре предметлары буенча, дәрестән тыш эшчәнлек) укыту чаралары сатып алынды.»;

түбәндәге эчтәлекле 28.3 пункт өстәргә:

«28.3. Авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында, «Мәгариф» милли проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында табигый-фәнни һәм технологик юнәлешле мәгариф үзәкләрендә эшләү һәм эшләтү чаралары

Авыл җирендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмаларында, «Мәгариф» милли проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында табигый-фәнни һәм технологик юнәлешле мәгариф үзәкләре булдыру һәм эшләтү чаралары кысаларында 2021 - 2023 елларда Татарстан Республикасында «Үсеш ноктасы» табигый-фәнни һәм технологик юнәлешле 347

мәгариф үзәге төзеләчәк (2021 елда - 114 мәктәп базасында, 2022 елда - 117 мәктәп базасында, 2023 елда - 116 мәктәп базасында).

«Үсеш ноктасы» үзәкләрен төзү, беренче чиратта, түбән белем бирү нәтиҗәләрен күрсәтүче авыл җирлегендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары базасында гамәлгә ашырыла. Гомуми белем бирү оешмалары базасында «Үсеш ноктасы» үзәкләрен төзү түбәндәге юнәлешләр буенча эшчәнлек алып бара:

әлеге оешмаларны «Математика һәм информатика» һәм «Табигый-фәнни предметлар» («Табигый фәннәр») өлкәләре предметлары, өстәмә белем бирү программалары буенча төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерү өчен билгеләнгән җиһазлар комплектлары белән тәэмин итү;

күрсәтелгән предметлы өлкәләрдән, балаларга өстәмә белем бирү өлкәсендә укучыларны практик яктан әзерләүне камилләштерү өчен методик материаллар, кейслар, практик биремнәр эшләү һәм тарату.»;

түбәндәге эчтәлекле 28.4 пункт өстәргә:

«28.4. «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында «Кванториум» балалар технопаркларының гомуми белем бирү оешмалары базасында булдыру чаралары

Гомуми белем бирү оешмасы базасында «Кванториум» балалар технопаркы (алга таба - Мәктәп Кванториумы) - ул белем бирү моделе, ул укучыларда табигый-фәнни, математик, мәгълүмати белемлелекне үстерү, тәнкыйди һәм креатив фикерләүне формалаштыру, табигый-фәнни һәм технологик юнәлештәге күнекмәләрне камилләштерү өчен гомуми белем бирү эчтәлеген киңәйтүне тәэмин итә. Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмалары базасында Мәктәп Кванториумнары челтәрен булдыру «Табигый-фәнни предметлар»(«Табигый фәннәр»),» Математика һәм информатика»,» Технология «һәм табигый-фәнни һәм техник юнәлештәге өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыру өченгомуми белем бирү оешмасын укыту һәм тәрбия чаралары, шул исәптән югары технологияле заманча җиһазлар белән тәэмин итү; укучыларның әлеге предмет өлкәләреннән, балаларга өстәмә белем бирү өлкәләреннән уку предметлары буенча гамәли әзерләүне камилләштерү өчен методик материаллар, кейслар, практик биремнәр эшләү һәм тарату чараларыннан гыйбарәт.

Мәктәп Кванториумнарын төзү әлеге гомуми белем бирү оешмаларында белем бирүнең сыйфатын яхшырту өчен шартлар булдыруны күздә тота, белем алучыларның табигый-фәнни һәм техник юнәлештәге уку предметларын, табигый-фәнни һәм техник юнәлештәге өстәмә белем бирү программасы үзләштерүдә, шулай ук «Технология», «Информатика», «Физика», «Химия», «Биология», «Астрономия» һәм башка предметлар буенча уку материалын гамәли яктан эшләтеп җибәрү мөмкинлекләрен киңәйтә. Төбәк мәгарифенең конкурентлык сәләтен һәм Татарстан Республикасының гомуми белем сыйфаты буенча алдынгы төбәкләр исәбенә керүен тәэмин итәчәкләр.

2021 - 2023 елларда Татарстан Республикасында түбәндәге гомуми белем бирү оешмалары базасында өч Мәктәп Кванториумын төзү планлаштырыла:

Казан шәһәре Вахитов районының «98 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе (татар-рус)» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының 2 нче лицей муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 1 нче лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе.»;

30 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«30. «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Цифрлы белем бирү мохите» төбәк проектын гамәлгә ашыру (шул исәптән гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында цифрлы белем бирү мохитенең максатчан моделен гамәлгә кертү; «IT-куб» балалар үсешенең төп үзәкләрен булдыру; цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен белем бирү оешмаларын матди-техник база белән тәэмин итү)

«Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Цифрлы белем бирү мохите» төбәк проекты 2024 елга барлык төр һәм дәрәҗәләрдәге белем бирүнең югары сыйфатын һәм һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итә торган заманча һәм имин санлы белем бирү мохите булдыруга юнәлтелгән.

«Цифрлы белем бирү мохите» төбәк проектын гамәлгә ашыру кысаларында цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү планлаштырыла, ул Татарстан Республикасы территориясендә барлык мәгариф оешмаларында белем алучылар, педагоглар һәм административ-идарә персоналы өчен «цифрлы компетенцияләр» профильләрен булдырырга, индивидуаль укыту планнарын (программаларын) конструкцияләргә һәм гамәлгә ашырырга, шул исәптән аттестацион чаралар узганда онлайн-курслар нәтиҗәләрен исәпкә алу хокукы белән, административ, идарә итү һәм тәэмин итү процессларын автоматлаштырырга; белем бирү сыйфатын бәяләү процедураларын үткәрергә мөмкинлек бирәчәк. Мәгариф оешмаларының хисаплылыгын электрон рәвешкә күчерү һәм аны автомат рәвештә формалаштыру юлы белән белем бирү оешмалары эшчәнлеген оптимальләштерү тәэмин ителәчәк.

Татарстан Республикасында белем бирү сыйфатын арттыру максатларында барлык мәгариф оешмалары тотрыклы һәм тиз интернет-тоташу белән тәэмин ителәчәк. Барлык типтагы белем бирү оешмалары рәсми сайтларның мәгълүмати тулылыгын һәм функциональ мөмкинлекләрен яңартачак.

2019 - 2020 елларда Татарстан Республикасында 110 белем бирү оешмасы (54 гомуми белем бирү һәм 56 һөнәри белем бирү оешмасы) базасында цифрлы белем бирү мохитенең максатчан моделе кертелде.

2021 - 2022 елларда цифрлы белем бирү мохитен гамәлгә кертү өчен 78 белем бирү оешмасын (69 гомуми белем бирү һәм 9 һөнәри белем бирү оешмасы) матди-техник база белән тәэмин итү планлаштырыла.

2024 елга Татарстан Республикасының барлык муниципаль берәмлекләрендә гомуми белем һәм урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында цифрлы белем бирү мохитенең максатчан моделе кертеләчәк.

2020 елда «Әлмәт политехника техникумы» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе базасында «IT-куб» балаларга цифрлы белем бирү үзәге төзелде. Аны булдыру зарурлыгы хәзерге дөньяның мәгълүматлаштыру һәм компьютерлаштыру дәрәҗәсен күтәрү, шулай ук балаларны һәм яшүсмерләрне IT-иҗатка төрле юнәлештәге җәлеп итүгә юнәлдерелгән мәктәптән тыш эшнең яңа системасын

формалаштыру буенча чаралар һәм чаралар комплексын гамәлгә ашыруның актуальлеге белән бәйле.

2022 елда «Алабуга» сәнәгать-җитештерү тибындагы махсус икътисадый зона» акционерлык җәмгыяте (алга таба - акционерлык җәмгыять) базасында «IT-куб-Алабуга» балаларга цифрлы белем бирү үзәген төзү планлаштырыла. Әлеге үзәкне төзүнең актуальлеге акционерлык җәмгыять резидентларының һәм IT-белгечләрдә Кама инновацион территориаль-җитештерү кластерының үсә баручы ихтыяҗлары белән аңлатыла.

«IT-куб» балалар IT-иҗат үзәкләрендә белем бирү хезмәтләре түбәндәге юнәлешләр буенча күрсәтеләчәк:

Python программалаштыру,

Java программалаштыру нигезләре

VR / AR-кушымталар эшләү,

мобиль эшләнмә,

системалы администрирование,

цифрлы гигиена һәм зур мәгълүматлар белән эшләү,

С-охшаш телләрдә программалаштыруның база күнекмәләре.

Күрсәтелгән чараларны гамәлгә ашыру үсеп килүче буын арасында цифрлаштыру өлкәсендә компетенцияләрне (заманча мәгълүмат технологияләре, ясалма интеллект, зур күрсәткечләр, болытлы киңлекләр, программалаштыру һәм административ операцияләр) инфраструктур-эчтәлекле дәрәҗәдә алга җибәрүне тәэмин итәргә мөмкинлек бирәчәк.»;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Ярдәмче программа чараларын финанслау күләме федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 214 638 293,48 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:

2014 ел - 17 205 591,64 мең сум;

2015 ел - 18 902 517,8 мең сум;

2016 ел - 18 161 160,9 мең сум;

2017 ел - 18 684 936,6 мең сум;

2018 ел - 20 796 481,8 мең сум;

2019 ел - 21 922 502,2 мең сум;

2020 ел - 30 383 867,24 мең сум;

2021 ел - 32 398 109,7 мең сум;

2022 ел - 32 674 691,1 мең сум;

2023 ел - 3 508 434,5 мең сум.

2023 – 2025 елларга акчалар күләме фараз характерында, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»;

5 нче таблицада:

33-34 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «33. | Цифрлы, табигыйфәнни, гуманитар һәм технологик профильләрдәге төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен матди-техник базасын яңарткан авыл җирлегендә һәм кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмалары саны, мең берәмлек | - | - | - | - | - | 0,097 | 0,139 | 0,253 | 0,37 | 0,486 | 0,5 | - |
| 34. | Цифрлы, табигыйфәнни, гуманитар һәм технологик профильле төп һәм өстәмә гомуми белем бирү программалары белән кертелгән укучылар саны, мең кеше | - | - | - | - | - | 26,568 | 38,4 | 55,2 | 83,4 | 97,9 | 98,9 | -»; |

түбәндәге эчтәлекле 56 - 60 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «56. | Гомуми белем бирү оешмаларының квалификация күтәрү узган педагогик хезмәткәрләре өлеше, шул исәптән һөнәри осталыкны өзлексез күтәрү үзәкләрендә, процент | - | - | - | - | - | - | - | 12 | 20 | 30 | 40 | - |
| 57. | Цифрлы белем бирү мохитен кертү максатларында җиһазланган гомуми белем бирү оешмалары өлеше, процент | - | - | - | - | - | - | - | 1,87 | 5,61 | 5,61 | 5,61 | - |
| 58. | Цифрлы белем бирү мохитенең федераль мәгълүмат-сервис плат- | - | - | - | - | - | - | - | - | 10 | 15 | 20 | - |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | формасына керү мөмкинлеге бирү юлы белән сыйфат белеме алу өчен тигез шартлар тудырылган белем алучылар өлеше, процент | | | | | | | | | | | | |
| 59. | Цифрлы белем бирү мохитенең федераль мәгълүмат-сервис платформасы сервисын кулланучы педагогик хезмәткәрләр өлеше, процент | - | - | - | - | - | - | - | - | 10 | 20 | 40 | - |
| 60. | Төп гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашырганда цифрлы белем бирү мохитенең федераль мәгълүмат-сервис платформасы сервисларыннан файдаланучы мәгариф оешмалары өлеше, процент | - | - | - | - | - | - | - | - | 10 | 20 | 30 | -»; |

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә) ;

«2014 - 2025 елларга өстәмә белем бирүне үстерү, инвалид балаларга белем бирүне дә кертеп, һәм әлеге өлкә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында (алга таба - ярдәмче программа):

ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, ярдәмче программасын финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, ярдәмче программасын финанслау күләмнәре | Ярдәмче программа чараларын финанслау күләмнәре федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 2 909 861,9 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:<br>2014 ел - 139 168,88 мең сум;<br>2015 ел - 388 317,6 мең сум;<br>2016 ел - 529 023,0 мең сум;<br>2017 ел - 487 193,9 мең сум;<br>2018 ел - 522 533,83 мең сум;<br>2019 ел - 161 670,69 мең сум;<br>2020 ел - 445 959,2 мең сум;<br>2021 ел - 106 717,6 мең сум;<br>2022 ел - 107 920,2 мең сум;<br>2023 ел - 21 357,0 мең сум.<br>2023 – 2025 елларга акчалар күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»; |

«Ярдәмче программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашыруның көтелгән ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» юлында:

утыз беренче абзацта «45» саннарын «15» саннарына алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«балаларда һәм яшьләрдә сәләтләрне һәм талантларны ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү буенча төбәк үзәкләре, «Кванториум» технопарклары һәм «IT-куб» үзәкләре эшчәнлеген 8 процентка кадәр арттыру;

башлангыч һөнәри ориентациягә йөз тоткан, шул исәптән «Киләчәккә билет» программасы кысаларында, чаралар күргән төп һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларның өлешен 37 процентка кадәр арттыру;

2 бүлектә:

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. «Мәгариф» илкүләм проекты кысаларында «Һәр баланың уңышы» төбәк проектын гамәлгә ашыру (шул исәптән сәләтле балаларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү үзәкләрен булдыру; стационар кванториумнар булдыру; балаларны үстерүнең төп үзәкләрен булдыру; «Кванториум» мобиль технопаркларын төзү; өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы үзәкләр булдыру, югары белем бирү оешмалары базасында)

«Һәр баланың уңышы» төбәк проекты Россия Федерациясе халыкларының рухи-әхлакый кыйммәтләре, тарихи һәм милли-мәдәни традицияләр нигезендә гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү буенча «Мәгариф» илкүләм проектының максатына ирешүгә юнәлтелгән. «Һәр баланың уңышы» төбәк проектында баланың иртә һөнәри ориентациясе механизмнарын һәм «Киләчәккә билет» һәм «Проектория» проектларын гамәлгә ашыру кысаларында сайлап алынган һөнәри компетенцияләр нигезендә индивидуаль уку планын үстерү каралган. Проектларны гамәлгә ашыруда икътисадның реаль секторы вәкилләре, әйдәп баручы

фәнни эшлекләләр, уйлап табучылар һәм эшкуарлар актив катнашачак. Укучылар югары технологияле тармаклар белән таныша, үзләрен гамәли бурычларны хәл итүдә сынап карый, кызыклы тармак һәм һөнәр сайлый алачак.

Өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыру өчен дистанцион технологияләрне куллану практикасы киңәя, бу сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балаларның кимендә 70 процентын өстәмә белем белән тәэмин итү мөмкинлеге бирәчәк.

Илнең технологик үсешенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган балаларның төп күнекмәләрен һәм компетенцияләрен формалаштыру максатларында төбәк проекты кысаларында федераль бюджеттан субсидияләр рәвешендә Татарстан Республикасы территориясендә кимендә өч «Кванториум» балалар технопаркы һәм бер «Кванториум» мобиль технопаркы төзү каралган.

Төбәк проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә барлык балалар өчен дә тарихи һәм милли-мәдәни традицияләргә, Россия Федерациясе халыкларының рухи-әхлакый кыйммәтләренә таяна торган гармонияле белем бирү мохите, шулай ук төзелә торган яңа технологик торышта алга китеш юнәлешләре өчен алшартлар булган гармонияле белем бирү мохите тәэмин ителәчәк.

2020 елда Казанда Татарстан Республикасы Хөкүмәте һәм «Талант һәм уңыш» мәгариф фонды арасында төзелгән Килешү кысаларында сәләтле балаларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү буенча республика үзәге булдырылды. Сәләтле балаларны ачыклау һәм аларга ярдәм итү буенча республика үзәге сәләтле балалар һәм Татарстан Республикасы яшьләре белән системалы эшне камилләштерү, күренекле сәләтлелек һәм югары квалификацияле балаларны һәм яшьләрне ачыклау, белем бирү программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, балаларга һәм яшьләргә индивидуаль продюсерлык ярдәмен тәэмин итү, алдынгы сәләтлелекне һәм югары белемле балаларны һәм яшьләрне алга таба үстерүне тәэмин итү өчен партнерлык челтәрен үстерү максатларында формалаштырыла.

Күрсәтелгән үзәкнең эшчәнлеге «Перспектива» Татарстан Республикасы балалар һәм яшьләренең интеллектуаль-иҗади потенциалын үстерү һәм гамәлгә ашыру концепциясе һәм «Талантларның Казан ачык университеты 2.0» АНО гомуми координациясе нигезендә алып барылачак, ул Фәнни-эксперт советы аша фәнни-эксперт озатуын һәм «Фән», «Мәдәният һәм сәнгать», «Спорт» юнәлешләре буенча белем бирү программаларын эшләүне тәэмин итә. Белем бирү программаларын оештыру һәм үткәрү өчен, тиешле укыту-лаборатория базасы һәм мөлкәт комплексы булган «Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының Олимпия үзәге» дәүләт автоном гомуми белем бирү учреждениесенең «Дуслык» савыктыру-белем бирү комплексы башлангыч бирәчәк.

2020 елда Чаллыда «Кванториум» балалар технопаркы мәйданчыгында мобиль кванториумнар булдыру чаралары кысаларында автомобиль станциясе базасында күчмә технопарк төзеләчәк, ул балаларны инженер юнәлеше программаларына өйрәтүне гамәлгә ашыручы, шулай ук техник юнәлешле мәктәп һәм өстәмә белем бирү учреждениеләре педагогларын өстәмә әзерләүне һәм практик юнәлешле укытуны гамәлгә ашыручы мобиль технопарк төзеләчәк. Мобиль технопаркның белем бирү юнәлешләре исемлеге: VR, «Промдизайн», «Геоквантум», «Аэроквантум», «Робоквантум», «IT-квантум», «Хайтек».

Югары белем бирү оешмалары базасында өстәмә гомуми белем бирү программаларын гамәлгә ашыра торган үзәкләр булдыру чаралары кысаларында 2020 елда «Казан (Идел буе) федераль университеты» федераль дәүләт автоном югары белем бирү учреждениесе базасында үзәк булдырылды.

Үзәк төзү максатларына югар һөнәри белем бирү оешмалары базасында биоген инженерия, машина фикерләве, мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати иминлек өлкәсендә 18 яшькә кадәрге балаларның сәләтләрен һәм талантларын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны үстерү буенча нәтиҗәле система булдыру, күрсәтелгән категориядәге балаларны күрсәтелгән өлкәләрдә фәнни-тикшеренү һәм инновацион эшчәнлеккә җәлеп итү керә.

Үзәкнең эшчәнлеге түбәндәгеләргә мөмкинлек бирәчәк:

1. 18 яшькә кадәрге балалар арасында максатчан һөнәри юнәлешле эш алып барырга;

2. Күрсәтелгән өлкәләрдә сәләтләрен һәм талантларын күрсәткән балалар өчен өстәмә белем бирүнең һәркем файдалана алырлык мохитен тәэмин итәргә;

3. Фәнни-тикшеренү һәм инновация эшчәнлеген үстерү өчен уңай шартлар тудырырга;

4. WorldSkills таләпләрен һәм әзерлек дәрәҗәсен исәпкә алып, күрсәтелгән компетенцияләр буенча балаларга өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашырырга;

5. Үзәк базасында хезмәт базары таләпләре һәм тыңлаучыларның теләкләре белән билгеләнә торган индивидуаль белем бирү траекториясе идеясен гамәлгә ашырырга.

Талантлы яшьләр арасында потенциалны үстерү һәм фәнни-тикшеренү һәм инновацион эшчәнлеккә ярдәм итү үзәкләрен төзү нәтиҗәсе булачак.»;

түбәндәге эчтәлекле 19 пункт өстәргә:

«19. «Мәгариф» илкүләм проектының «Заманча мәктәп» федераль проекты кысаларында «Кванториум» балалар технопаркларының гомуми белем бирү оешмалары базасында булдыру чаралары

Гомуми белем бирү оешмасы базасында «Кванториум» балалар технопаркы (алга таба - Мәктәп Кванториумы) - ул белем бирү моделе, ул укучыларда табигый-фәнни, математик, мәгълүмати белемлелекне үстерү, тәнкыйди һәм креатив фикерләүне формалаштыру, табигый-фәнни һәм технологик юнәлештәге күнекмәләрне камилләштерү өчен гомуми белем бирү эчтәлеген киңәйтүне тәэмин итә. Мәктәп Кванториумнары челтәрен булдыру гомуми белем бирү оешмаларын укыту һәм тәрбия чаралары белән тәэмин итү буенча, шул исәптән «Табигый-фәнни предметлар»(«Табигый фәннәр»), «Математика һәм информатика», «Технология» предмет өлкәләрен тормышка ашыру, табигый-фәнни һәм техник юнәлештәге өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыру; табигый-фәнни һәм техник юнәлештәге өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру; укучыларның әлеге предмет өлкәләреннән, балаларга өстәмә белем бирү программалары буенча гамәли әзерлеген камилләштерү өчен методик материаллар, кейслар, практик биремнәр эшләү һәм тарату чараларыннан гыйбарәт.

Мәктәп Кванториумнарын төзү гомуми белем бирү оешмаларында белем бирү сыйфатын күтәрү өчен шартлар камилләштерүне күздә тота, белем алучыларның табигый-фәнни һәм техник юнәлештәге уку предметларын, табигый-фәнни һәм техник юнәлештәге өстәмә белем бирү программаларын үзләштерүдә, шулай ук «Технология», «Информатика», «Физика», «Химия», «Биология», «Астрономия» һәм башка предметлар буенча уку материалын практик яктан эшләтеп җибәрү мөмкинлекләрен киңәйтә. Төбәк мәгарифенең конкурентлык сәләтен һәм Татарстан Республикасының гомуми белем сыйфаты буенча алдынгы төбәкләр исәбенә керүен тәэмин итәчәкләр.

2021 - 2023 елларда Татарстан Республикасында түбәндәге гомуми белем бирү оешмалары базасында өч Мәктәп Кванториумын төзү планлаштырыла:

Казан шәһәре Вахитов районының «98 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе (татар-рус)» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының 2 нче лицей муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе;

«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының 1 нче лицее» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе.»;

ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Ярдәмче программа чараларын финанслау күләмнәре федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 2 909 861,9 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:

2014 ел - 139 168,88 мең сум;
2015 ел - 388 317,6 мең сум;
2016 ел - 529 023,0 мең сум;
2017 ел - 487 193,9 мең сум;
2018 ел - 522 533,83 мең сум;
2019 ел - 161 670,69 мең сум;
2020 ел - 445 959,2 мең сум;
2021 ел - 106 717,6 мең сум;
2022 ел - 107 920,2 мең сум;
2023 ел - 21 357,0 мең сум.

2023 – 2025 елларга акчалар күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»;

5 бүлек таблицасында:

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «1. | Өстәмә белем алган 5 яшьтән 18 яшькә кадәрге балалар өлеше, процент | 105,3 | 103,2 | 101 | 72 | 73 | 74 | 75 | 67,5 | 69 | 72 | 73 | 80»; |

30 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «30. | «Киләчәккә билет» проектын гамәлгә ашыруны исәпкә алып, сайлап алынган һөнәри компетенцияләр (эшчәнлекнең һөнәри өлкәләре) нигезендә индивидуаль укыту планын төзү буенча тәкъдимнәр алган балалар саны, үсә баручы нәтиҗә белән, мең кеше | - | - | - | - | - | 7,5 | 15»; | | | | | |

түбәндәге эчтәлекле 36 - 38 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «36. | Башлангыч һөнәри ориентациягә, шул исәптән «Киләчәккә билет» программасы кысаларында, юнәлдерелгән чаралар белән колачланган төп һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алучылар өлеше, процентлар | - | - | - | - | - | - | - | 30 | 30 | 30 | 37 | - |
| 37. | Балаларны балалар һәм яшьләрнең сәләтләрен ачыклау, аларга ярдәм итү һәм аларны үстерү буенча төбәк үзәкләре, «Кванториум» технопарклары һәм «IT-куб» үзәкләре эшчәнлеге белән колачлау, процент | - | - | - | - | - | - | - | 9 | 9 | 8 | 8 | - |
| 38. | Балаларга өстәмә белем бирүне шәхсиләштерелгән финанслау системасы кысаларында өстәмә белем бирү сертификатлары бирә торган Россия Федерациясе субъектлары саны, берәмлек | - | - | - | - | - | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | 1 | -»; |

ярдәмче программага 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

«2014 - 2025 елларга һөнәри һәм югары уку йортыннан соңгы белем бирүне үстерү һәм әлеге өлкә хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү» ярдәмче программасында (алга таба - ярдәмче программа):

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре (Ярдәмче программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары)» юлына түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Алдан һөнәри әзерлек үзәкләре эшчәнлеге белән колачланган гражданнар санын 20 251 берәмлеккә кадәр арттыру;

эшчәнлек төре һәм алынган компетенцияләр буенча мәшгуль урта һөнәри белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын тәмамлаучыларның өлешен 62,5 процентка кадәр арттыру;

демонстрация имтиханы йомгаклары буенча милли яисә халыкара стандартларга туры килә торган дәрәҗәне күрсәткән урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларының өлеше 15 процентка кадәр арттыру»;

2 бүлекнең «Ярдәмче программаларның төп чаралары характеристикасы» пунктының икенче абзацында «Россия Федерациясе Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Оборона-сәнәгать комплексы оешмаларының җыелма реестрына кертелгән оешмалар исемлеген раслау турында» 2013 елның 5 февралендәге 137 номерлы боерыгы белән расланган оборона-сәнәгать комплексы оешмаларының җыелма реестрына кертелгән оешмалар исемлегенә кергән профессиональ белем бирү оешмалары өстенлекле тәртиптә хупланачак».» сүзләрен «Профильле эш бирүчеләр оборона-сәнәгать комплексы оешмаларының җыелма реестрына кертелгән оешмалар исемлегенә кергән һөнәри белем бирү оешмалары өстенлекле тәртиптә хупланачак.» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 81 - 83 пунктлар өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «81. | Алдан һөнәри әзерлек үзәкләре эшчәнлеге белән колачланган гражданнар саны | - | - | - | - | - | - | - | 8 251 | 12 251 | 16 251 | 20 251 | - |
| 82. | Эшчәнлек төре һәм алынган компетенцияләр буенча мәшгуль урта һөнәри белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларын тәмамлаучылар өлеше | - | - | - | - | - | - | - | 62,4 | 62,5 | 62,6 | 62,7 | - |
| 83. | Демонстрацион имтихан йомгаклары буенча илкүләм яисә халыкара стандартларга туры килә | - | - | - | - | - | - | - | 3 | 5 | 10 | 15 | -»; |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | торган дәрәҗәне күрсәткән урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларында укучылар өлеше | | | | | | | | | | | | |

«2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасы кысаларында социаль һәм инженерлык инфраструктурасын үстерү» ярдәмче программасында (алга таба - ярдәмче программа):

ярдәмче программа паспортында:

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, ярдәмче программасын финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, ярдәмче программасын финанслау күләмнәре | Ярдәмче программа чараларын финанслау күләмнәре федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 116 471 913,12 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:<br>2014 ел - 3 276 380,3 мең сум;<br>2015 ел - 10 287 192,8 мең сум;<br>2016 ел - 12 319 020,9 мең сум;<br>2017 ел - 8 141 860,8 мең сум;<br>2018 ел - 15 892 374,91 мең сум;<br>2019 ел - 20 146 126,41 мең сум;<br>2020 ел - 18 140 215,1 мең сум;<br>2021 ел - 16 153 040,9 мең сум;<br>2022 ел - 12 113 382,3 мең сум;<br>2023 ел - 2 318,7 мең сум.<br>2023 – 2025 елларга акчалар күләме фараз характерында, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»; |

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре» (Ярдәмче программа нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары) юлының илле икенче абзацында «1435» саннарын «2323» саннарына алмаштырырга;

3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Ярдәмче программаны ресурслар белән тәэмин итүне нигезләү

Ярдәмче программа чараларын финанслау күләмнәре федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән 116 471 913,12 мең сум тәшкил итәчәк, шул исәптән еллар буенча:

2014 ел - 3 276 380,3 мең сум;

2015 ел - 10 287 192,8 мең сум;

2016 ел - 12 319 020,9 мең сум;
2017 ел - 8 141 860,8 мең сум;
2018 ел - 15 892 374,91 мең сум;
2019 ел - 20 146 126,41 мең сум;
2020 ел - 18 140 215,1 мең сум;
2021 ел - 16 153 040,9 мең сум;
2022 ел - 12 113 382,3 мең сум;
2023 ел - 2 318,7 мең сум.

2023 – 2025 елларга акчалар күләме фараз характерында, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә»;

5 бүлекнең 47 - 47.2 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «47. | Физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү өчен матди-техник база яңартылачак гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны, шул исәптән: | - | - | - | - | - | - | - | 706 | 828 | 789 | | |
| 47.1. | авыл җирлегендә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны | - | - | - | - | - | - | - | 706 | 828 | 789 | | |
| 47.2. | кече шәһәрләрдә урнашкан гомуми белем бирү оешмаларында укучылар саны | - | - | - | - | - | - | - | 0 | 0 | 0»; | | |

1 нче, 11 нче кушымталарны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин